СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

19 декабрь 2025

КАРАР

№ 15

Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының «Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы,Шеңшеңәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 99 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында
(2023 елның 27 феврале 71 нче, , 2024 елның 16 июле 106 нчы,2024 елның 30 октябре 109 нчы,2025 елның 14 мае,131 нче номерлы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 нче ноябре 994 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 17 нче декабре 26 нчы номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 нче декабрендәге 99 нчы номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр

авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «21091» санын «23201» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы — Р.Х.Салихҗанов